**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

09.12.2019 1347-п

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектлары: Чупай, Ерсубай, Кондыз, Казакъ, Оштырма, Лубян, Бурец (Бура), Мәләкәс, Шукралинка (Чаллы), Бәтке, Тукай муниципаль районының Кече Шилнә авыл җирлегендәге исемсез күлләрнең яр линиясе урнашкан урынын (су объекты чикләрен) билгеләү турында

Россия Федерациясе Су кодексының 26, 65 статьялары, «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль законның 32 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында»гы федераль законның 32 статьясының 1, 3 – 13, 15, 15(1) өлешләре нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан дәүләт кадастр исәбен алып баруга, хокукларны дәүләт теркәвенә алуга, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып баруга һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләрне тапшыруга вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органына (аның территориаль органнарына) җибәрелә яки тапшырыла торган документларны тапшыру кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1532 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яр линиясе урнашкан урынны (су объекты чикләрен), аны билгеләү очракларын һәм ешлыгын билгеләү һәм Җирлектә су объектларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 29 апрелендәге 377 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлектә су объектларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 10 гыйнварындагы 17 номерлы карары, Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан федераль мөлкәттәге һәм Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан су объектларын яки аларның өлешләрен саклау чараларын гамәлгә ашыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтен гамәлгә ашыру буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2010 елның 29 сентябрендәге 425 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан

Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектлары: Чупай, Ерсубайкино, Бобровка, Казакъ, Оштoрма, Лубянка, Бурец (Бура), Мәләкәс, Шукралинка (Чаллы), Бәтке, Тукай муниципаль районының Кече Шилнә авыл җирлегендәге исемсез күлләрнең яр линияләрен (су объекты чикләрен), су саклау зоналары һәм яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү турында» 2019 елның 19 мартындагы 1-Ф/2019 номерлы дәүләт контракты кысаларында башкарылган эш йомгаклары буенча Максатчан фараз күрсәткечләренә ирешүгә юнәлдерелгән һәм 2019 елда су мөнәсәбәтләре өлкәсендәге Россия Федерациясенең аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акча хисабыннан финанслана торган чаралар исемлеге нигезендә,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектлары: Чупай, Ерсубай, Кондыз, Казакъ, Оштырма, Лубян, Бурец (Бура), Мәләкәс, Шукралинка (Чаллы), Бәтке, Тукай муниципаль районының Кече Шилнә авыл җирлегендә 16:39:101001:611 һәм 16:39:103601:268 кадастр номерлары беркетелгән җир кишәрлекләре территорияләрендә ике исемсез күлнең яр линиясе урнашкан урынын (су объекты чикләрен) билгеләргә.
2. Су объектларын саклау бүлегенә (О.Г. Германова) материалларны билгеләнгән тәртиптә дәүләт су реестрына кертү өчен Су ресурсларының федераль агентлыгына җибәрергә.
3. Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендәге проектларны пропагандалау бүлегенә (Л.Н.Мөлекова) әлеге боерыкны татар теленә тәрҗемә итәргә.
4. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (М.М. Шәехов) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.
5. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.М.Шиһаповка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков